**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Түбән Кәминкә авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнары җыены**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлеге составына керүче **Кара Чишмә** авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**02 ноябрь 2023 ел** **№ 4**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлегенең **Кара Чишмә авылы** торак пунктында гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

2024 елда Түбән Кәминкә авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә үзара салым кертергә I төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операцияләрендә булганнардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрергә:

1. **Кара Чишмә** торак пунктында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тоту, хезмәт күрсәтү (юл кырыйларын чабу, юл-урам челтәрендәге юл кырыйларын норматив хәлгә китерү, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу чыгымнары;
2. **Кара Чишмә** торак пунктында урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, торак пунктларда урам утларына кулланган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;
3. «Атау » чишмәсен ремонтлау **(Кара Чишмә авылы)** чишмә территориясен санитар-саклау зонасын төзекләндерү, койманы ремонтлау һәм буяу, павильон урнаштыру, павильонны тышлау, каты түшәлгән юллар төзү, җир кишәрлекләрен рәсмиләштерү, проект-смета документлары өчен түләү) Кара Чишмә торак пунктында югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) үтәү өчен кирәкле материаллар сатып алу.
4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлегенең рәсми сайтында

Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
ТР Чирмешән муниципаль районы
Түбән Кәминкә авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Халиков